ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 гыйнвар, 2019 ел № 29/8

Шәһәр Советының 2014 елның 09 декабрендәге 35/8 санлы Карары белән расланган товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2013 елның 05 апрелендәге «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе 2 өлеше һәм 69 маддәсе нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2014 елның 09 декабрендәге 35/8 санлы Карары белән расланган товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алуны формалаштыру, үтәү һәм гамәлгә ашыруны контрольдә тоту тәртибе турында Нигезнамәгә (Шәһәр Советының 2015 елның 15 апрелендәге 39/9, 2016 елның 24 февралендәге 6/7, 2018 елның 08 ноябрендәге 27/8 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«23. Вәкаләтле орган, заказ бирүче контракт нигезендә тәэмин итүчене (башкаручыны, подрядчыны) билгеләү буенча аерым функцияләрне, шул исәптән, сатып алу, бердәм мәгълүмати системада һәм электрон мәйданчыкта Федераль законда каралган мәгълүмат һәм

электрон документларны эшләү өчен, тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) ябык ысуллар белән билгеләүдә катнашырга чакыру җибәрү, тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) билгеләүне тәэмин итүгә бәйле башка функцияләрне башкару өчен махсус оешма җәлеп итәргә хокуклы. Шул ук вакытта сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссия төзү, контрактның башлангыч (максималь) бәясен, предметын һәм башка мөһим шартларын билгеләү, контракт проектын раслау, сатып алу турында документлар һәм контрактны имзалау заказчы тарафыннан башкарыла.».

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев